# «Авылым гүзәллеге» («Великолепие села»)

# марафоннар фестивале нигезләмәсе

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

**1.1. Исеме**: «Авылым гүзәллеге» («Великолепие села») марафоннар фестивале.

**1.2. Оештыручылар**: «Татнетны үстерү фонды» коммерцияле булмаган оешмасы, 2024 елда гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе гранты ярдәмендә.

**1.3. Үткәрү максаты**: Татар авыллары халкы арасында милли мирасны һәм халык иҗатын популярлаштыру.

**1.4. Үткәрү вакыты**: 2025 елның 1-21 мартында.

**1.5. Катнашу формасы**: Катнашу Нигезләмә таләпләре нигезендә социаль челтәрләрдә материалларны урнаштыру юлы белән башкарыла.

**1.6. Максатчан аудитория**: Туган җирләренең мәдәни мирасын саклау һәм аларны таныту белән кызыксынган һәркем.

**1.7. Тематик юнәлешләр**:

1) Авылым тарихы – История моего села (төбәкнең милли тарихы, гореф-гадәтләр) – 3 көн;

2) Авылым шәхесләре – Личности моего села (авылның танылган шәхесләре, сәнгать, мәгариф, фән, спорт һ.б. өлкәләрдә эшлекләләре һәм авылымның Ватанны саклаучы геройлары) - 6 көн;

3) Авылым осталары – Мастера моего села (декоратив-гамәли сәнгать осталары һәм аларның иҗат җимешләре) – 3 көн;

4) Авылым риваятьләре – Легенды и мифы моего села (халык авыз иҗаты) – 3 көн;

5) Авылдашларым иҗаты – Творчество моих односельчан (музыка кораллары, костюмнар, әсәрләр, җырлар, биюләр) – 3 көн;

6) Авылым чишмәләре – Родники моего села (чишмәләрнең тарихи кыйммәте) – 3 көн.

## 2. КАТНАШУ ШАРТЛАРЫ

**2.1. Катнашучыларга таләпләр**:

- Катнашучыларның яшь чикләүләре юк;
- Катнашучы тәкъдим ителгән материалның авторы булырга тиеш;
- Катнашучыларның материаллары марафонның сайланган юнәлеше тематикасына туры килергә тиеш.

**2.2. Материалларны тәкъдим итү форматлары**:

- Видео – дәвамлылыгы 10 минутка кадәр;
- Текст материаллар – күләме 3000 символга кадәр иллюстрацияләр (фото, рәсемнәр/сурәтләр) белән;
- Фотосурәтләр – югары сыйфатта (кимендә 300 dpi), тасвирлама белән, марафон темасына ярашлы.

Барлык материаллар «ВКонтакте» (https://vk.com) һәм/яисә «Миллион татар» (https://million.tatar) социаль челтәрләрендә катнашучының шәхси аккаунтында әлеге Нигезләмә таләпләренә ярашлы рәвештә татар телендә урнаштырыла.

Оештыручылар марафон кысаларында катнашу юнәлешләрен һәм биремнәрне тәкъдим итәчәкләр.

**2.3. Техник таләпләр**:

1) Видеоматериаллар видеохостингта (мәсәлән: VK Видео, RuTube, YouTube һ.б.) урнаштырылырга, аларга сылтама конкурс язмасында бирелергә тиеш;

2) Социаль челтәрләрдәге язмалар #АвылымГүзәллеге хэштегын һәм марафонның тематик юнәлешләре хэштегларын (#АвылымШәхесләре, #АвылымТарихы һ.б.) үз эченә алырга тиеш;

**2.4.** Катнашучылар материал урнаштырыла торган социаль челтәрнең кагыйдәләрен үтәргә тиешләр.

**2.5. Материалларны урнаштыру сроклары**: 2025 елның 1 мартыннан 21 мартына кадәр.

**2.6. Публикацияләр саны**: 21 көн дәвамында катнашучы сайланган юнәлеш буенча татар телендә материал урнаштыра. Катнашучы, көнендә урнаштырырга өлгермәгән очракта, материалны күрсәтелгән срокларда башка

көнне урнаштыра ала (2.5 п. кара). Һәр язма уникаль булырга һәм әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килергә тиеш.

**2.7. Материалларга хокуклар**: Оештыручы катнашучыларның материалларын әлеге проектны таныту кысаларында авторлар белән өстәмә килешүләр төземичә файдаланырга һәм материалларны «Авылым гүзәллеге» электрон мәйданчыгында урнаштырырга хокуклы.

**2.8. Этика кодексы**: кимсетү, көч куллануны пропагандалау, дискриминация булган материалларны, шулай ук Россия Федерациясе законнарына каршы килә торган башка материалларны урнаштыру тыела.

## 3. ЭШЛӘРНЕ БӘЯЛӘҮ ҺӘМ БҮЛӘКЛӘҮ

**3.1. Бәяләү критерийлары**:

- Марафонның игълан ителгән тематик юнәлешләренә туры килүе – 0-5 б.;
- Материалларны барлык юнәлешләрдә дә әзерләп тәкъдим итү – 3-21 б.;
- Материалның тирән эчтәлекле һәм дөрес булуы – 0-10 б.;
- Материалны тәкъдим итүнең оригиналь һәм креатив булуы – 0-10 б.;
- Бизәлеш сыйфаты (видео, фотосурәтләр, текстлар) – 0-10 б.;
- Катнашкан көннәр саны – 1-21 б.

**3.2. Жюри**: Жюри составы оештыручылар тарафыннан мәдәният, тарих, этнография һәм медиа өлкәсендәге экспертлар арасыннан формалаша.

**3.3. Этаплар**:

1) 22-30 март – Беренче этап: югарыда әйтелгән критерийлар нигезендә марафонның һәр юнәлеше буенча иң яхшы эшләрне сайлап алу.

2) 31 март – Икенче этап: жюри әгъзалары тарафыннан җиңүчеләрне билгеләү.

3) 1-21 апрель – Өченче этап: җиңүчеләрне һәм финалистларны күчмә бүләкләүләр.

**3.4. Бүләкләү**:

- Марафонның һәр юнәлешендә җиңүче истәлекле приз һәм диплом ала;
- Иң яхшы эшләр «Авылым гүзәллеге» («Великолепие села») электрон мәйданчыгында урнаштырылачак;

- Бүләкләү тантаналары марафоннар сериясе ахырында муниципаль районнарга барып үткәреләчәк, анда җиңүчеләргә һәм финалга чыгучыларга призлар һәм сертификатлар тапшырылачак.

**3.5. Электрон мәйданчык**: тәкъдим ителгән материаллар нигезендә электрон мәйданчык булдырылачак, анда теләгән һәркем авыл территорияләрендә яшәүчеләрнең милли традицияләре, мәдәни мирасы һәм иҗаты буенча уникаль контент белән таныша алачак.

## 4. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

**4.1. Шартлар үзгәрү**: Оештыручылар үзләрендә әлеге Нигезләмәгә үзгәртүләр кертү хокукын калдыралар.

**4.2. Элемтә өчен мәгълүмат**: «Татнетны үстерү фонды», тел.: +79600456353, e-mail: fondtatnet@yandex.ru, рәсми сайт: https://tat-i.net/tt, Фондның рәсми берләшмәсе: https://vk.com/tatnet, Фестиваль берләшмәсе: https://vk.com/avilimguzallege, электрон мәйданчык адресы: https://avilim-guzallege.ru.

**4.3** Әлеге Нигезләмә «Авылым гүзәллеге» марафоннар фестивалендә катнашу шартларын билгели торган рәсми документ булып тора. Марафоннарда катнашырга карарга кылган катнашучы автомат рәвештә әлеге Нигезләмәнең барлык шартлары белән килешә һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын бирә.